**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**2021 елның 20 декабре** **№57**

Күгеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 4 мартындагы 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2021 елның 17 августындагы 49 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Күгеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Күгеш авыл җирлеге Советы Регламенты нигезендә Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Күгеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 4 мартындагы 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә (2021 елның 17 августындагы 49 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында( http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Күгеш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында: Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1 йорт (авыл җирлеге администрациясе бинасы), Күгеш авылы, Совет урамы, 17 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.А.Гатауллин**